# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Янил авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

02 декабрь, 2024 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Янил авыл җирлегенең Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 650 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү);

2. урам яктыртуны ясау (Янил авылында урам яктыртуны карап тоту, ясау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3. су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Янил авылының Үзәк урамында су белән тәэмин итү системалары төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

4. торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Янил авылындагы юлларга вак таш, асфальт-бетон түшәмә җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту; юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

5. тротуарлар ясау, ремонтлау (җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту; тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

6. торак пункт территориясен төзекләндерү (Янил авылында күпләп ял итү урыннарын һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

7. традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Янил авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

3. Әлеге карарны Янил авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Янил авыл җирлеге башлыгы И.Х.Курбанов